КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 3 октябрь г.Казань № 1222

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2013 – 2023 елларга Татарстан Республикасында газ-мотор ягулыгы базарын үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 26 апрель, 283 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2013 – 2023 елларга Татарстан Республикасында газ-мотор ягулыгы базарын үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 26 апрель, 283 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 13 декабрь, 980 нче; 2014 ел, 25 декабрь, 1027 нче; 2015 ел, 30 декабрь, 1021 нче; 2016 ел, 1 март, 125 нче; 2016 ел, 3 июнь, 369 нчы; 2017 ел, 21 март, 164 нче; 2018 ел, 23 июль, 580 нче; 2019 ел, 2 июль, 526 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасында газ-мотор ягулыгы базарын үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында»

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Бу карарга теркәлгән «Татарстан Республикасында газ-мотор ягулыгы базарын үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын (алга таба – дәүләт программасы) расларга.»;

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгын дәүләт программасының җаваплы башкаручысы итеп билгеләргә.»;

3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Республика башкарма хакимият органнарына, законнарда билгеләнгән тәртиптә автотранспорт техникасын үзәкләштерелгән сатып алганда дәүләт катнашындагы оешмаларга, алар карамагындагы оешмаларга автотранспорт техникасын үзәкләштерелгән сатып алуны, компримланган һәм сыекландырылган табигый газдан файдаланучы автотранспорт техникасын өстенлекле сатып алуны, шулай ук компримировкаланган һәм сыекландырылган табигый газда эшләү өчен гамәлдәге автотранспорт техникасын яңадан җиһазлауны тәэмин итәргә.»;

4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары башлыкларына тиешле территориядә дәүләт программасын гамәлгә ашыруны тәэмин итә торган чаралар күрүне тәкъдим итәргә.»;

әлеге карар белән расланган «2013 – 2023 елларга Татарстан Республикасында газ-мотор ягулыгы базарын үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын яңа редакциядә бәян итәргә (карарга теркәлгән).

2. Бу карарга теркәлгән исемлек нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты актлары һәм актларныңаерым нигезләмәләре үз көчен югалткан дип танырга.

3. Бу карар 2024 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 26 апрель, 283 нче карары белән расланды (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 3 октябрь, 1222 нче карары редакциясендә)

## «Татарстан Республикасында газ-мотор ягулыгы базарын үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасы

### «Татарстан Республикасында газ-мотор ягулыгы базарын үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын гамәлгә ашыру өлкәсендә стратегик өстенлекләр

### I. Газ-мотор ягулыгы базарын үстерү өлкәсендә агымдагы халәтне бәяләү

«Татарстан Республикасында газ-мотор ягулыгы базарын үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасы (алга таба - Татарстан Республикасы дәүләт программасы) Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Энергетиканы үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасын раслау турында» 2014 елның 15 апрелендәге 321 номерлы карары белән расланган «Энергетиканы үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2021 елның 29 октябрендәге 3052-б номерлы боерыгы белән расланган 2050 елга кадәр парник газлары чыгарып ташлау дәрәҗәсе түбән булган Россия Федерациясенең социаль-икътисадый үсеш стратегиясе, «2030 елга кадәр Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү стратегиясен раслау турында» 2015 елның 17 июнендәге 40-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба - Стратегия-2030) нигезендә эшләнде.

Климат хәлен яхшырту, парник газлары чыгару дәрәҗәсен киметү һәм углерод нейтральлегенә ирешү Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерүнең өстенлекле юнәлешләреннән берсе булып тора. Әлеге өстенлекне тәэмин итү өчен юнәлешләрнең берсе - ягулыкның түбән үлчәмле чыганакларын куллануга күчү.

Газ-мотор ягулыгы сыйфатында компримирланган табигый газны (алга таба - КТГ) һәм сыекландырылган табигый газны (алга таба - СТГ) куллану нефть ягулыгын куллануга перспектив альтернатива булып тора.

2023 елның 1 гыйнварына КТГ да эшли торган автомобильләр паркы 28,0 млн. берәмлектән артык тәшкил итә.

Россия Федерациясе Энергетика министрлыгы мәгълүматы буенча, 2023 елның 1 гыйнварына Россия Федерациясендә 60,0 млн. берәмлектән артык транспорт чарасы теркәлгән, шуларның 290,5 мең берәмлеге (гомуми санның 0,4 проценты) КТГны газ-мотор ягулыгы сыйфатында куллана.

2023 елның 1 гыйнварына Татарстан Республикасында газ-мотор ягулыгын (метанны) 13,0 мең берәмлектән артык транспорт чарасы файдаланыла.

Табигый газны газ-мотор ягулыгы сыйфатында кулланунын иң зур потенциалы ачыкланган:

эре сәнәгать автотранспорт предприятиеләре, шул исәптән торак-коммуналь хуҗалык һәм юлхуҗалыгы предприятиеләре урнашкан республика әһәмиятендәге шәһәрләрдә (Казан, Чаллы шәһәрләрендә);

төбәк сәгәгать, йөк ташу һәм пассажирлар йөртү компанияләре, торак-коммуналь һәм юл хуҗалыгы муниципаль предприятиеләре урнашкан муниципаль районнарда (Азнакай, Әлмәт, Буа, Бөгелмә, Биектау, Алабуга, Зәй, Зеленодольск, Лениногорск, Түбән Кама, Тукай);

Татарстан Республикасының эре автотранспорт, төзелеш һәм юл предприятиеләрен үз эченә алган автотранспорт комплексында;

Татарстан Республикасының эре агросәнәгать холдингларын, агросәнәгать предприятиеләрен һәм крестьян-фермер хуҗалыкларын үз эченә алган агросәнәгать комплексында;

Татарстан Республикасы территориясе буенча узучы федераль һәм төбәк әһәмиятендәге автомобиль юлларында.

Хәзерге вакытта Татарстан Республикасында гомуми җитештерүчәнлеге 390,0 млн. куб метр булган 45 автомобиль газ тутыру компрессор станциясе (алга таба - АГТКС) урнашкан.

Әлеге АГТКС Казанда, Чаллы шәһәрендә, Азнакай шәһәрендә, Әлмәт шәһәрендә, Алексеевск шәһәр тибындагы поселогында, Бөгелмә шәһәрендә, Буа шәһәрендә, Алабуга шәһәрендә, Зәй шәһәрендә, Зеленодольск шәһәрендә, Лениногорск шәһәрендә, Түбән Кама шәһәрендә, Нурлат шәһәрендә, Актаныш, Әлмәт, Әлки, Апас, Биектау, Алабуга, Яшел Үзән, Лаеш, Минзәлә, Мамадыш, Питрәч, Тукай муниципаль районнарында урнашкан.

Хәзерге вакытта Татарстан Республикасы территориясендә табигый газ белән тәэмин итүдә эшләүче 214 транспорт чарасы файдаланыла.

СТГда эшләүче техниканы тәэмин итү өчен дүрт криоген ягулык салу станциясе эшли (алга таба - КриоАЯС).

Моннан тыш, Татарстан Республикасында 2022 елда гомуми җитештерүчәнлеге елына 25 000 тонна булган табигый газны (Биектау һәм Теләче муниципаль районнары) сыекландыру буенча ике комплекс гамәлгә кертелгән.

Дәүләт программасы газ-мотор автомобиль транспорты өчен җитештерү һәм сату инфраструктурасын үстерү һәм Татарстан Республикасы территориясендә файдаланыла торган һәм җитештерелә торган газ-мотор автомобиль транспортын арттыру өчен җайга салу, инвестиция, инфраструктура һәм технологик шартлар булдыруга юнәлтелгән, бу, үз чиратында, Татарстан Республикасының углерод нейтральлеге дәрәҗәсен арттырырга мөмкинлек бирәчәк.

Татарстан Республикасы дәүләт программасының төп максаты – автомобиль транспортының әйләнә-тирә мохиткә һәм халыкның сәламәтлегенә тискәре йогынтысы дәрәҗәсен тотрыклы киметүне тәэмин итү һәм автотранспорт чаралары белән ташуның иң зур икътисадый нәтиҗәлелегенә ирешү, шулай ук транспорт

чараларын газга (метанга) сатып алу һәм яңадан җиһазлау исәбенә Татарстан Республикасы автотранспорт паркын яңарту һәм мотор ягулыгы буларак КТГ һәм СТГ куллануны арттыру.

Россия Федерациясендә гамәлгә кертелә торган ярдәм чараларын исәпкә алып, газ-мотор ягулыгында кулланыла торган транспорт чаралары санының артуы фаразлана. Шул ук вакытта мондый транспортның үсеше табигый газның үсеш алган җитештерү һәм сату инфраструктурасын булдыруны да таләп итәчәк. Татарстан Республикасы дәүләт программасы әлеге бурычны хәл итүгә юнәлтелгән.

## II. Татарстан Республикасы дәүләт программасын гамәлгә ашыру өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт сәясәте өстенлекләрен һәм максатларын тасвирлау

Татарстан Республикасы дәүләт программасының өстенлекләре Россия Федерациясе Президентының «2030 елга кадәр чорга Россия Федерациясе үсешенең милли максатлары турында» 2020 елның 21 июлендәге 474 номерлы Указына, Федерациясе Хөкүмәтенең 2021 елның 1 октябрендәге 2765-б номерлы боерыгы белән расланган Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2024 елга кадәрге чорда һәм 2030 елга кадәрге план чорына Россия Федерациясе үсешенең илкүләм максатларына ирешү буенча Россия бердәм планына, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2021 елның 29 октябрендәге 3052-б номерлы боерыгы белән расланган 2050 елга кадәр парник газлары чыгарып ташлау дәрәҗәсе түбән булган Россия Федерациясенең социаль-икътисадый үсеш стратегиясенә, Стратегия-2030, шулай ук Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Энергетиканы үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасын раслау турында» 2014 елның 15 апрелендәге 321 номерлы карары белән расланган «Энергетиканы үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасына туры килә.

Татарстан Республикасы икътисады очраша торган актуаль проблемаларны бетерү, шулай ук Татарстан Республикасы социаль-икътисадый үсешенең стратегик максатларына һәм бурычларына ирешү өчен Татарстан Республикасы дәүләт программасы күрсәткечләренең структурасы һәм системасы билгеләнгән.

Татарстан Республикасы дәүләт программасы максатлары:

Татарстан Республикасында автотранспорт чараларына газ мотор ягулыгы буларак кысылган табигый газны һәм сыекландырылган табигый газны өстенлекле файдалану өчен шартлар тудыру;

кысылган табигый газны һәм сыекландырылган табигый газны җитештерү һәм сату инфраструктурасын булдыру;

газ-мотор техникасы паркы, газ-мотор ягулыгы җитештерү куәтләре, газ белән тәэмин итү инфраструктурасы, сервис челтәре һәм газ-мотор транспортын сатканнан соң аңа хезмәт күрсәтү системаларының синхронлаштырылган үсешен тәэмин итү;

автомобиль транспортының әйләнә-тирә мохиткә һәм халык сәламәтлегенә тискәре йогынтысы дәрәҗәсен тотрыклы киметүне тәэмин итү;

Газ-мотор ягулыгы базарын үстерү чараларын гамәлгә ашыру нәтиҗәсе - Татарстан Республикасында эксплуатацияләнә торган газ-мотор ягулыгында

транспорт чаралары санына ирешү, 19 000 берәмлектән ким булмаган, ягулык салу инфраструктурасы объектлары саны - кимендә 66 берәмлек АГТКС һәм 13 КриоАЯС, елына 170,0 млн. тоннага кадәр КТГ сатуны тәэмин итү, елга 84,0 мең тоннага кадәр - табигый газны яндыру буенча кимендә 1 комплекс файдалануга тапшыру, елына 5,4 мең тоннага кадәр зарарлы (пычраткыч) матдәләрне автотранспорт чаралары белән чыгаруны киметү.

## III. Стратегик өстенлекләр, илкүләм максатлар һәм Стратегия-2030 максатлары, Россия Федерациясе дәүләт программалары күрсәткечләре белән үзара бәйләнеш турында белешмәләр

Татарстан Республикасы дәүләт программасының максатлары һәм бурычлары Россия Федерациясе Президентының «2030 елга кадәр чорга Россия Федерациясе үсешенең илкүләм максатлары турында» 2020 елның 21 июлендәге 474 номерлы Указы белән билгеләнгән 2030 елга кадәр чорга Россия Федерациясе үсешенең илкүләм максатларын, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2021 елның 1 октябрендәге 2765-б номерлы боерыгы белән расланган Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2024 елга кадәрге чорда һәм 2030 елга кадәрге план чорына Россия Федерациясе үсешенең илкүләм максатларына ирешү буенча Россия бердәм планын, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2021 елның 29 октябрендәге 3052-б номерлы боерыгы белән расланган 2050 елга кадәр парник газларының чыгарылыш дәрәҗәсе түбән булган Россия Федерациясенең социаль-икътисадый үсеш стратегиясен, Стратегия-2030 исәпкә алып формалаштырылды.

Татарстан Республикасы дәүләт программасын гамәлгә ашыру түбәндәгеләргә ирешергә юнәлдереләчәк:

2030 елга кадәр чорга Россия Федерациясе үсешенең милли максатлары - «Тормыш өчен уңайлы һәм куркынычсыз мохит» дигән темага әйләнә-тирә мохиткә һәм кеше сәламәтлегенә иң зур тискәре йогынты ясый торган зарарлы матдәләр чыгарып ташлауларны киметү буенча ике мәртәбә;

Стратегия-2030 максатлары:

«пространство, реаль капитал: балансланган территориаль-пространство үсеше мохитнең конкурентлык сәләте югары дәрәҗәдә булуын тәэмин итә; инфраструктура глобаль рәвештә конкурентлыкка сәләтле. Җитештерү фондлары нәтиҗәле файдаланыла»;

«Пассажирлар хәрәкәтләре һәм йөкләр ташу өчен таләп ителә торган файдалану мөмкинлеген тәэмин итә торган транспорт-коммуникация системасы сыйфаты күрсәткечләренең югары дәрәҗәсенә ирешелде»

## IV. Дәүләт идарәсе бурычлары, газ-мотор ягулыгы базарын үстерү өлкәсендә аларны нәтиҗәле хәл итү ысуллары

Татарстан Республикасы дәүләт программасы максатларына ирешү өчен түбәндәге бурычлар хәл ителә:

Татарстан Республикасы икътисадында структур үзгәрешләрне тәэмин итү, озак вакытлы үсешнең инновацион чыганакларын булдыру һәм, арзанрак һәм экологик газ-мотор ягулыгын куллану исәбенә республика предприятиеләренең конкурентлык сәләтен арттыру;

озак сроклы заказлар портфелен булдыру, яңа технологияләр кертү һәм импортны алмаштыру программаларын гамәлгә ашыру нигезендә республика машина төзелеше предприятиеләренең җитештерү куәтләрен киңәйтү исәбенә газ мотор техникасын үстерүне стимуллаштыру;

Татарстан Республикасы таяну транспорт челтәрен колачлый торган заманча газ заправкасы һәм сервис инфраструктурасын булдыру;

транспорт чараларының әйләнә-тирә мохит торышына тискәре йогынтысын киметү.

«Татарстан Республикасында газ-мотор ягулыгы базарын үстерү»
Татарстан Республикасы дәүләт программасы
паспорты

1. Төп нигезләмәләр

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасы дәүләт программасы кураторы | Коробченко Олег Владимировичны – Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министры |
| Татарстан Республикасы дәүләт программасының җаваплы башкаручысы | Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы |
| Татарстан Республикасы дәүләт программасын гамәлгә ашыру чоры | I этап: 2013 – 2023 еллар;<br>II этап: 2024 – 2026 еллар |
| Татарстан Республикасы дәүләт программасы максатлары | Татарстан Республикасында автотранспорт чараларына газ мотор ягулыгы буларак кысылган табигый газны һәм сыекландырылган табигый газны өстенлекле файдалану өчен шартлар тудыру.<br>Кысылган табигый газны һәм сыекландырылган табигый газны җитештерү һәм сату инфраструктурасын булдыру.<br>Газ-мотор техникасы паркы, газ-мотор ягулыгы җитештерү куәтләре, газ белән тәэмин итү инфраструктурасы, сервис челтәре һәм газ-мотор транспортын сатканнан соң аңа хезмәт күрсәтү системаларының синхронлаштырылган үсешен тәэмин итү<br>Автомобиль транспортының әйләнә-тирә мохиткә һәм халык сәламәтлегенә тискәре йогынтысы дәрәҗәсен тотрыклы киметүне тәэмин итү |
| Татарстан Республикасы дәүләт программасын гамәлгә ашыруның бөтен чорында финанс белән тәэмин ителеш күләмнәре | I этап: 17 302 150,0 мең сум;<br>II этап: 26 824 254,5 мең сум |

| | |
|---|---|
| Россия Федерациясе үсешенең илкүләм максатлары, 2015 елның 17 июнендәге 40-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән расланган 2030 елга кадәр Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү стратегиясенең (алга таба – Стратегия-2030), Россия Федерациясе дәүләт программасы, Татарстан Республикасы дәүләт программасы максатлары белән бәйләнеш | Татарстан Республикасы дәүләт программасын гамәлгә ашыру түбәндәгеләргә ирешергә юнәлдереләчәк:<br>1) Россия Федерациясе Президентының «2030 елга кадәр чорга Россия Федерациясе үсешенең илкүләм максатлары турында» 2020 елның 21 июлендәге 474 номерлы Указы белән расланган 2030 елга кадәр чорга Россия Федерациясе үсешенең илкүләм максатларына: әйләнә-тирә мохиткә һәм кеше сәламәтлегенә иң зур тискәре йогынты ясый торган куркыныч пычраткыч матдәләр чыгаруларны киметү буенча «Яшәү өчен уңайлы һәм имин мохит» (алга таба – Илкүләм максат);<br>2) Стратегия-2030 максатларына:<br>«пространство, реаль капитал: балансланган территориаль-пространство үсеше мохитнең конкурентлык сәләте югары дәрәҗәдә булуын тәэмин итә; инфраструктура глобаль рәвештә конкурентлыкка сәләтле. Җитештерү фондлары нәтиҗәле файдаланыла»;<br>«Пассажирлар хәрәкәтләре һәм йөкләр ташу өчен таләп ителә торган файдалану мөмкинлеген тәэмин итә торган транспорт-коммуникация системасы сыйфаты күрсәткечләренең югары дәрәҗәсенә ирешелде»;<br>3) Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Энергетиканы үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасын раслау турында» 2014 елның 15 апрелендәге 321 номерлы карары белән расланган «Энергетиканы үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасына |

## 2. Татарстан Республикасы дәүләт программасы күрсәткечләре

| Т/с | Күрсәткеч исеме | Күрсәткеч дәрәҗәсе | Арту / кимү билгесе | Үлчәү берәмлеге (Үлчәү берәмлекләре гомумроссия классификаторы буенча) | База күрсәткече | | Еллар буенча күрсәткеч әһәмияте | | | Документ | Күрсәткечкә ирешү өчен җаваплы | Илкүләм максатлар, Стратегия-2030 максатлары күрсәткечләре белән бәйләнеш | Билге муниципаль берәмлек тарафыннан гамәлгә ашырыла | Мәгълүмат системасы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | күрсәткече | елы | 2024 | 2025 | 2026 | | | | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 |
| Автотранспорт чараларында газ-мотор ягулыгы буларак кысылган табигый газ өстенлекле файдалану өчен шартлар тудыру | | | | | | | | | | | | | | |
| 1. | Татарстан Республикасында оешмалар тарафыннан сатып алынган, КТГ белән эшли торган автотранспорт чаралары саны | Татарстан Республикасы дәүләт программасы (алга таба – ДП) | арта бара торган | данә | 450 | 2023 | 450 | 500 | 550 | Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Энергетиканы үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасын раслау турында» 2014 елның 15 апрелендәге 321 номерлы карары белән расланган «Энергетиканы үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасы | Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы, Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы | Стратегия-2030 максатлары кысаларында «Пространство, реаль капитал: балансланган территориаль-пространство үсеше мохитенең конкурентлык сәләтенең югары булуын тәэмин итә; инфраструктура глобаль конкурентлыкка сәләтле. Җитештерү фондлары нәтиҗәле файдаланыла», «Пассажирлар хәрәкәтләре һәм йөкләр ташу өчен | юк | юк |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | | | | | таләп итеlә торган файдалану мөмкинлеген тәэмин итә торган транспорт-коммуникация системасы сыйфаты күрсәткечләренең югары дәрәҗәсенә ирешелде» | | |
| 2. | «Газпром газмотор ягулыгы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте белән төзелгән партнерлык килешүе булган һәм газмотор ягулыгы базарын үстерүгә стимул бирү программаларын гамәлгә ашыруда катнашкан яңадан җиһазландыру һәм техник хезмәт күрсәтү пунктлары чыгымнарының бер өлешен субсидияләү механизмнарын кулланып гамәлгә | илкүләм проект составына керми торган федераль проект (алга таба – ИП керми торган ФП) | арта бара торган | данә | 700 | 2023 | 1 200 | 1 300 | 1 400 | Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Энергетиканы үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасын раслау турында» 2014 елның 15 апрелендәге 321 номерлы карары белән расланган «Энергетиканы үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасы | Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы, яңадан җиһазландыру һәм техник хезмәт күрсәтү пунктлары (алга таба – ЯҖТХКП), «Газпром газомоторное топливо» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте (алга таба – «Газпром газомоторное топливо» ЖЧЖ), «Татарстан Республикасының Энергия ресурслары нәтиҗәлелеге технологияләр | Стратегия-2030 максатлары кысаларында «Пространство, реаль капитал: балансланган территориаль-пространство үсеше мохитнең конкурентлык сәлә-тенең югары булуын тәэмин итә; инфраструктура глобаль конкурентлыкка сәләт-ле. Җитештерү фондлары нәтиҗәле файдаланыла», «Пассажирлар хәрәкәтләре һәм йөкләр ташу өчен таләп итеlә торган | юк | юк |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | ашырыла торган яңадан җиһазландыру кысаларында физик затлар-ның, юридик затларның (шул исәптән муниципаль милектәге һәм дәүләт милкен-дәге), индиви-дуаль эшмә-кәрләрнең газ-мотор ягулы-гын куллануга күчерелгән автотранспорт чаралары саны* | | | | | | | | | | е үзәге» дәүләт автоном учреждениесе (алга таба – «ТР ЭТҮ» ДАУ) | файдалану мөмкинлеген тәэмин итә торган транспорт-коммуникация системасы сыйфаты күрсәткечләре нең югары дәрәҗәсенә ирешелде» | | |
| 3. | Муниципаль милектәге һәм дәүләт милкендәге газ-мотор ягулыгын куллануга күчерелгән автотранспорт чаралары саны* | ДП | арта бара торган | данә | 300 | 2023 | 300 | 300 | 300 | Россия Феде-рациясе Хө-күмәтенең «Энергетика-ны үстерү» Россия Федерациясе дәүләт про-граммасын раслау турында» 2014 елның 15 ап-релендәге 321 номерлы карары белән расланган «Энергетика-ны үстерү» Россия Федерациясе дәүләт | Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы, ЯҖТХКП, «Газпром газомоторное топливо» ҖЧҖ, «ТР ЭТҮ» ДАУ | Стратегия-2030 максат-лары кысала-рында «Прост-ранство, реаль капитал: балансланган территориаль-пространство үсеше мохит-нең конку-рентлык сәлә-тенең югары булуын тәэмин итә; инфра-структура глобаль конку-рентлыкка сә-ләтле. Җитеш-терү фондлары нәтиҗәле | юк | юк |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | | | программасы | | файдаланыла», «Пассажирлар хәрәкәт-ләре һәм йөкләр ташу өчен таләп ителәторган файда-лану мөмкин-леген тәэмин итә торган транспорт-коммуникация системасы сыйфаты күрсәткечлә-ренең югары дәрәҗәсенә ирешелде» | | |
| 4. | Автотранспорт чараларының зарарлы (пычраткыч) матдәләр чыгаруын киметү | ДП | арта бара торган | мең тонна | 2,5 | 2023 | 3,0 | 3,5 | 4,0 | Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Энергетика-ны үстерү» Россия Федерациясе дәүләт про-граммасын раслау турында» 2014 елның 15 апрелендәге 321 номерлы карары белән расланган «Энергетика-ны үстерү» Россия Феде-рациясе дәүләт программасы | Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы, Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы | Илкүләм максат кысаларында | юк | юк |
| 5. | Эксплуатациял әнә торган | ДП | арта бара | млн. куб метр | 85,0 | 2023 | 90,0 | 120,0 | 170,0 | Россия Федерациясе | Татарстан Республикасы | Илкүләм максат | юк | юк |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | АГСТКСен исәпкә алып, КТГ сату күләме | | торган | | | | | | | Хө-күмәтенең «Энергетика-ны үстерү» Россия Федерациясе дәүләт про-граммасын раслау турында» 2014 елның 15 апрелендәге 321 номерлы карары белән расланган «Энергетика-ны үстерү» Россия Феде-рациясе дәүләт программасы | Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы, «Газпром газомоторное топливо» ҖЧҖ | кысаларында | | |
| 6. | Газ-мотор ягулыгын куллану өлкәсендә дәүләт учреждениеләр енең һәм муниципаль учреждениеләр нең машина йөртүче-ләрен һәм жа-waплы затларын әзерләүне һәм яңадан әзер-ләүне оештыру* | ДП | арта бара торган | кеше | 300 | 2023 | 300 | 300 | 350 | Россия Феде-рациясе Хөкүмәтенең «Энергетика-ны үстерү» Россия Феде-рациясе дәүләт программасын раслау турында» 2014 елның 15 апрелендәге 321 номерлы карары белән расланган «Энергетика-ны үстерү» Россия Феде-рациясе дәүләт программасы | Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы, «ТР ЭТҮ» ДАУ | Илкүләм максат кысаларында | юк | юк |
| 7. | Автотранспорт чараларының техник торы- | ДП | арта бара торган | данә | 0 | 2023 | 1 000 | 1 500 | 2 000 | Россия Федерациясе Хөкүмәтенең | Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм | Илкүләм максат кысаларында | юк | юк |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | шын автоматлаштырылган контрольдә тоту системасы эшен оештыру һәм аңа техник ярдәм күрсәтү, дәүләт һәм муниципаль учреждениеләренең газ-мотор ягулыгы кулланыла торган автотранспорт чараларын эксплуатацияләү һәм максатчан файдалану нәтиҗәлелеген бәяләү* | | | | | | | | | «Энергетиканы үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасын раслау турында» 2014 елның 15 апрелендәге 321 номерлы карары белән расланган «Энергетиканы үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасы | сәүдә министрлыгы, «ТР ЭТҮ» ДАУ | | | |
| 8. | Дәүләт һәм муниципаль учреждениеләренең кысылган табигый газ белән эшли торган автотранспорт чараларын эксплуатацияләү таләпләрен бозуларга монитринг үткәрү һәм экспертиза ясау* | | | хисап материаллары саны, берәмлек | 0 | 2023 | 1 | 1 | 1 | Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Энергетиканы үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасын раслау турында» 2014 елның 15 апрелендәге 321 номерлы карары белән расланган «Энергетиканы үстерү» | сынау лабораторияләре (килешү буенча), «ТР ЭТҮ» ДАУ | Илкүләм максат кысаларында | юк | юк |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | | | Россия Федерациясе дәүләт программасы | | | | |
| Автотранспорт чараларында газ-мотор ягулыгы буларак кысылган табигый газ өстенлекле файдалану өчен шартлар тудыру | | | | | | | | | | | | | | |
| 1. | Сатып алынган СТГ белән эшли торган йөк техникасы саны* | ДП | арта бара торган | данә | 200 | 2023 | 171 | 125 | 170 | Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Энергетика-ны үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасын раслау турында» 2014 елның 15 апрелендәге 321 номерлы карары белән расланган «Энергетика-ны үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасы | кушымта | Илкүләм максат кысаларында | юк | юк |
| 2. | СТГ белән эшләү өчен яңадан җиһаз-ландырылган йөк техникасы саны* | ДП | арта бара торган | данә | 0 | 2023 | 290 | 600 | 800 | Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Энергетика-ны үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасын раслау турында» 2014 елның 15 апрелендәге 321 номерлы карары белән | кушымта | Илкүләм максат кысаларында | юк | юк |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | | | расланган «Энергетика-ны үстерү» Россия Феде-рациясе дәүләт программасы | | | | |
